СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

13сентябрь,1997ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 103 (8115) | Бәясе билгеләнгәнчә

# Бер эшне дә чиратка куймыйк!

*Ашлык - дәүләткә*

## Тагын ике хуҗалык

**Дәүләткә ашамлык бодае тапшыру буенча күтәренке заданиене тагын ике хуҗалык тутырды. Кичәге көнгә хәзерләүләр пунктына Кузнецов исемендәге хуҗалыктан 2040 тонна, «Заря»дан 1200 тонна яхшы сыйфатлы бодай керде.**

**Башка хуҗалыклар да дәүләткә ашлык тапшыруны эзлеклелек белән алып баралар. Кичәге көнгә район хуҗалыклары барлыгы 74 мең тоннага якын ашлык тапшырдылар һәм шуның 46 мең тоннадан күбрәге -ашамлык бодае. Иң куанычлысы шул, безнеңрайон элеккечә үк республикада бодайны иң күп хәзерләүче һәм аның сыйфаты буенча да беренчелекне тота.**



Минталип Фәйзуллин. Газетаны даими укып баручыларга бу фамилия таныш булыр. Яңа Иглай егетенең «ДОН» комбайннарыннан торган беренче район җыелма отряды составында эшләгәндә фидакарь хезмәте турында яздык без. Елның елында җәй комбайнда эшли иде ул. Быел районга яңа «Кейс» комбайннары кайткач та, Минталип шуларның берсенә утырырга карар кылды. Һәрвакыттагыча тырышып эшли егет: комбайны бункерыннан 16.700 центнер ашлык бушатуы да шул хакта сөйли.

Минталипны төп эш урыны «Агрохимсервис» АҖндә дә мактап туймыйлар. Үсемлекләрне саклау буенча механикалаштырылган отряд составында эшли ул. Хезмәте җиңел түгел: ЛТЗ - 55 тракторына тагылган француз бөркегечләре белән басуга агу - химикатлар сиптерү һәркемнең дә кулыннан килә торган эш түгел. Әмма Минталип сер бирми. Хәер, производствоның төрле тармакларында сыналган егет монда гына сыната димени инде?!

**Рәсемдә: механизатор М.Фәйзуллин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

*Терлекчелек кышка карый*

## КҮҢЕЛ ИТКӘЧ КУЛ ДА ҖИТӘ

«Правда» крестьян хуҗалыклары ассоциациясенең соңгы елларда терлекчелек өлкәсендә әллә ни ялтыраганы булмады. Ә менә кооперативларга берләшеп, нефтебазаның ярдәмче хуҗалыгы статусын да алгач хәл сизелерлек үзгәрде дияргә мөмкиң. Дөрес, продукция җитештерү һәм аны хәзерләүдә зур сикереш ясалмаса да, сөтчелектә узган елгы күрсәткечләрне узып эшләү, тармактагы тотрыклылык хәлнең алга таба тагын да ныгыячагына өмет уята. Товарлыклы - сөтчелек фермаларында терлек абзарларын кышка әзерләү кебек мөһим эшкә шактый ук җитди караулары бу өметне аеруча ныгыта. Быел хуҗалыкта товарлыклы - сөтчелек фермасындагы каралтыларның һәммәсенә кул тигән. Ике абзар үстерү һәм симертү группасы малларын бәйләүсез асрауга үзгәртеп корылган. Абзар идәннәрен бетонлап, яңа утлыклар көйләгәннәр. Малларны чыгарып йөртү өчен кардалар да иркен. Агач материалын табып биргәч, ремонтчылар аны яңабаштан эшләгәннәр. Карда эчендә дә утлыклар ясап куйганнар. Кыскасы, яшь терлекләрне карау күпкә мәшәкатьсезрәк булачак быел. Инде малларны җылы су белән тәэмин итү мәсьәләсен дә хәл кылуны гына кайгыртасы.

Савым сыерлар быелга элеккеге технология буенча асралачак. Шуңа күрә иң мөһиме тирес чыгару транспортерларының ышанычлы булуы турында кайгырту. Без булган көнне ремонтчылар аларын да тәртипкә китерү белән мәшгульләр иде. Әмма ул эшне тизрәк тотарга кирәклеге бәхәссез. Барлык абзарларны вакытында агартып чыгулары да игътибарга лаек.

Кыскасы, хуҗалыкта фермаларны, бигрәк тә мөгезле эре терлекләр абзарларын кышка әзерләү эшен игътибар үзәгенә алулары яхшы булган. Тик ул эшне эзлеклелек беләнрәк башкарганда нәтиҗә тагын да әйбәтрәк буласы иде - тотынган - тотынган һәр абзарны җиренә җиткереп чыгу кирәк.

Шулай да эшнең саллысы дуңгыз фермасында әле. Кышкы салкыннарга кадәр анда да азмы - күпме эш башкарырга мөмкин һәм хуҗалыкның бу тармагын җанландыру турында уйлаганда анысын һич тә сузарга ярамый.

**Р.МУЛЛИН.**

## Андреевкага да газ килде

Андреевканы газлаштыру эше авыл колхоз составында чакта ук башланган булса да, ул эшнең ниһаять тәгәлләнүе монда шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгы оештырылгач кына мөмкин булды. Димитровградның 14 нче махсуслашкан участогы көче белән башкарылган зур эшнең нәтиҗәсе күз алдында инде - атна башында комиссия авылның газлаштырылган йортларына зәңгәр ягулык бирергә мөмкин икәнлеген раслады. Әлегә илле йорт нигездә әзер һәм йорт хуҗаларын сөендереп, башкаларның да бу уңайлыктан файдаланырга өметен ныгытып авылның өч өендә плитәләр челтәр газыннан эшли башлады.

# АШАГАН БЕЛМИ, ТУРАГАН БЕЛӘ

## МСОда хезмәт хакы бирү мәсьәләсенә карата

Хуҗалыкара төзелеш оешмасында эшчеләргә хезмәт хакы бирүнең соңгы бер - ике елда аеруча кискенләшүе турында язганыбыз булды инде. Язмаслык та түгел иде шул,чөнки хезмәт хакын айныкын - айга тулысы белән биреп бара алмау нәтиҗәсендә оешманың үз эшчеләренә бурычы ел башына 1,9 миллиард сумга җыелган булган. Дөрес, ел уртасына ул 1,4 миллиард сумга калган калуын, әмма ай саен әзме - күпме аванслап килү генә бурычны кискен киметмәгәнлеге кемгә дә аңлашыла торгандыр. Өстәвенә, алачагың миллионнар була торып та кулыңа онытылганда бер йөз - ике йөз сум гына акча кереп торганда аның исен дә сизәргә өлгермисең бит. Шуңа күрә эшчеләрнең зур канәгатьсезлек белдерүләрен аңларга була. Тик шунысы гаҗәп, бу канәгатьсезлек оешмада җитәкчелек алышынганнан соң бигрәк тә сизелә башлады, хәтта забастовка ясарга җыенабыз, сезне дә чакырабыз, дип безгә дә мөрәҗәгать итүчеләр булды. Канәгатьсезлекнең нәкъ менә яңа башлык килгәннән соң артуының сәбәбен аңлавы кыен булса да, саннарга мөрәҗәгать итүне кирәк дип саныйбыз.

Июль аенда акчалата 296 миллион сум хезмәт хакы түләнгән. Моннан тыш, төзелеш материаллары өчен тотылган 88.500 мең сум, продукциялатә бирелгән 4 миллион, фатир хакы тәртибендә тотылган 21 миллион сум да шул ук хезмәт хакы исәбеннән.

Августта,төзүчеләр көне алдыннан 150 миллион сум акчалата хезмәт хакы алганнар. Әлбәттә, бәйрәм хөрмәтенә дә кеше башына 100 -150шәр генә мең акча тиюе бирәүне дә канәгатьләндермәгәндер инде, анысы белән килешәбез. Әмма яңа җитәкче килгәч кенә дә августта тагын 271 миллион сум акчалата түләнүен дә истән чыгарырга ярамый. Һәм бу юлы инде анысын кеше башына йөзәр мең иттереп түгел, әкемнең күпме алачагы булудан чыгып шуның 10 проценты исәбеннән таратулары гаделрәк булды дип уйларга кирәк. Шул ук августта төзелеш материаллары өчен 142 милллион сум чигерелгән. Бер айда МСОның үз кибете аркылы сатылган азык - төлек кенә дә 82 миллион сумлык булган, шул исәптән 2 тонна ак май, 200 килограмм сыр өләшенгән, хәзер сөтне дә исемлек буенча бирә башлаганнар, әле ипи һәм башка кайбер төр көндәлек кирәк азык - төлекне дә кибет аркылы исемлек буенча сатуны оештыру мәшәкатьләре белән йөриләр. Әле менә бер тонна колбаса кайтартканнар һәм анысы тагын күпмедер миллон сум хезмәт хакын каплаячак дигән сүз. Беренче сентябрь алдыннан акча бирелүен, бу атнада гына тагын акчалата 400 миллион сумнан күбрәк хезмәт хакы өләшенүен шулай ук бирәү дә инкарь итмәстер. Бу юлы да аңы пропорциональ рәвештә биргәч, алачагы зур булганнарның кулына тигән сумма элеккечә йөзәр мең сум гына булмады. Шулай итеп, оешманың 1 июльгә булган бурычы 1 миллиард сум калган. Инде 113 кешенең алачагы июль, август айлары өчен генә.

Бу саннарга шулай ваклап тукталуыбыз һич тә үзмаксат түгел. Эшчеләрнең канәгатьсезлеген дә яхшы аңлыйбыз, тик менә әле бер генә ай эшләргә өлгергән җитәкчедән оешманың ике ел буена җыелган бурычын беръюлы түләп бетерүен таләп итүләренә генә кул куя алмыйбыз. Ашаган белми, тураган белә дип юкка гына әйтмиләр бит.

## Хөрмәтле дуслар!

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу игълан ителде. Язылу бәясе ярты елга 26.4000, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**




***8 сентябрьдән 18 сентябрьгә кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасына льготалы язылырга мөмкин. Аның бәясе - 19.800 сум.***

Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.

## Синең кешеләрең, Норлат

# ТУГЪРЫЛЫК



Әгәр ул шул вакытта әйләнмичә, вакытны сузыбрак торса, мөгаен, туган авылы Киекледә үк калган да булыр иде.

Читтән килеп җирле мәктәптә укытучы булып эшләүче, үзешчән сәнгать түгәрәгендә бергә биеп йөрүче Алсу Хәбибулловнага Алабуга пединститутына кышкы сессиягә китәсе көннәрдә генә тотты да кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Алсуы да ризалашты да куйды.

Шулай итеп, кичәге сержант, хәзерге колхоз бригадиры ярдәмчесе белән укытучы кыз туй ясадылар.

Менә шунда гаиләне ничек тәэмин итәргә дигән сорау туа. Һәммәсе дә яхшы булсын өчен, ныклы терәк булу шарт. Бу терәк исә - эш. Димәк, чын һөнәр, даими торак табарга кирәк.

6 балалы - 6 уллы эшчән гаиләдә үскән Рафик бер хезмәттән дә курыкмый иде.

Чын һөнәр сайлаганчы 2 еллап вакыт узды. Алар гаиләләре белән Лениногорскига, нефтьче булып эшләүче Вазыйх агалары янына киттеләр. Рафик Вәлиәхмәтович хәзергә кадәр Лениногорск нефть чыгаручыларын җылы итеп искә ала: алар эшкә урнашу кыен булган 1976 елда аны үз эшче гаиләләренә кабул иттәләр, һөнәргә өйрәтәләр һәм Рафик 20 елдан артык шул һөнәргә тугърылык саклап яши.

Шул елларда аның хезмәт кенәгәсендә беренче язу пәйда булды да: скважиналарны җир асты ремонты буенча оператор итеп кабул ителде. Шуннан бирле бу кенәгәдә бары тик аның квалификацион разрядын күтәрү турында гына билгеләр. Тагы 1979 елда шул ук һөнәрдә аны туган ягы Норлатта яңа ачылган нефть - газ чыгару идарәсенә күчерү турында язу бар.

- Беренче адымнарыбызны ясаганда, төрле кыенлыклар да булды, аларны бик авыр кичерә идем,- дип искә ала Р.Хәмәтвәлиев. - Аның каравы, беренче кыр сезонында ук күп нәрсәгә өйрәндем, махсус әдәбият укыдым, иптәшләрем тәҗрибәсенә колак салдым. Осталык шулай акрынлап килде. Ә минем һәрчак үз эшемнең остасы буласым килә иде...

Рафикны Хезмәт Даны Ордены белән бүләкләүгә әзерләгән вакытта миңа (ул чакта мин НГДУның кадрлар бүлеге начальнигы идем) аның белән якыннан танышырга туры килде. Бар яктан да килгән иде ул: әйбәт костюм, ап - ак күлмәк, чиста итеп кырынган, пөхтә мыеклы, килешле чәчле, сабыр холыклы - һәммәсе ныклы, тәртипле, ышанычлы.

Эш урынында да шундый ул: тыныч, сабыр, пөхтә.

- 15 елдан артык Рафик Вәлиәхмәтович иң югары 6 нчы разряд буенча эшли,- дип сөйли, скважиналарга җир асты ремонты бригадасы мастеры Рафик Сингатуллин. - Әгәр сменада аның вахтасы икән, мин тулысынча ышанам: һәммә эш тиешенчә башкарылачак, һәр хезмәтне җиренә җиткереп үтәячәк. Бер сүз белән әйткәндә, ышанычлы кеше ул, чын белгеч тә. Ярдәмче оператор Халит Шәкүров һәм күтәрткеч машинисты Насыйх Гайсин да вахта буенча өлкән иптәшләре турында шундый фикердә.

Бу еллар эчендә аңарда ярдәмче (димәк, өйрәнчек!) булып күпләр эшләде. Хәзер алар үзләре вахта белән җитәкчелек итәләр, кайсылары мастер сыйфатында бригадалар белән җитәкчелек итәләр.

Рафик Хәмәтвәлиевның үзенә скважиналарны ремонтлау буенча мастер урыны тәкъдим иттеләр һәм итәләр дә. Әмма ул гел бер җавапны бирә: мин үз урынымда. Кеше урынын аласым килми.

Аның куллары белән йөзләгән скважина төзекләндерелде. Ә бу - тонналаган нефть дигән сүз. Нәкъ шундый әзерлекле белгечләр, чын хезмәткәрләр тырышлыгы нәтиҗәсендә «Норлатнефть» НГДУсы елдан - ел нефть чыгаруны арттыра бара.

Рафикның гаиләсендә дә дәрәҗәсе зур.

- Бик ышанычлы кеше инде,- ди Алсу Хәбибулловна ире турында. - 20 елдан артык бергә яшәү чорында төрле шартларда да мин гел шуңа инана килдем. Ул гына түгел, ага - энеләре дә шундыйлар. Алар һәммәсе эш өчен яралганнар. Чын хезмәт кешеләре.

Шунысын өсти алабыз: бертуган Хәмәтвәлиевларның икесе - нефтьчеләр, калганнары һәркайсы үз һөнәре буенча авыл хуҗалыгында эшлиләр. Ә язмабыз башында телгә алынган Вазыйх Мәскәү нефть һәм газ институтын тәмамлап, «Лениногорскнефть»тә әйдәп баручы инженер - ЦПКРС начальнигы урынбасары булып эшли. Дөрес, аның фамилиясе бераз бүтәнчәрәк языла - Мөхәммәтвәлиев. Алсу Хәбибулловна да кайчандыр үзе сайлаган һөнәргә тугъры калды. Хәзер ул Норлатта балалар бакчасы мөдире. Ә менә уллары Радик әтисе эзеннән китте - Казан дәүләт педагогия университетының III курсында укый, тарихчы булырга ниятли.

Ә нәрсә, безгә үз куллары белән тарихны тудыручылар кебек үк тарихчылар да кирәк.

**В.БУРАЙКИН.**

**Норлат шәһәре.**

**«Норлатнефть» НГДУсының скважиналарга җир асты ремонты операторы, III дәрәҗә хезмәт даны ордены кавалеры, нефть промышленносте отличнигы Рафик Хәмәтвәлиев.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**



Александр Ильмухин - «Агрохимсервис» АҖ ярдәмче хуҗалыгының иң алдынгы механизаторларының берсе. Иртә яздан алып кара көзгә кадәр басуда була ул. Җир сөрә, чәчә, аннан үсемлекләр карый. Тырышып эшли Александр.

Бүгенге көндә механизатор Ильмухин басуларны туңга сөрү белән мәшгуль.

**Рәсемдә: А.Ильмухин.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ИҢ БЕРЕНЧЕ КЕШЕ...

М.Шәймиев урыс православие чиркәве орденын алган бердәнбер мөселман димәкче булабыз. Русия тарихында мондый хәлнең булганы юк икән. Алексий II - нең М.Шәймиевкә әлеге орденны тапшыруын телевизордан карап утырганда, их, патриарх башына да татар түбәтәе кидертергә иде дип уйлап куйдым. Алексий II дә әдәп саклап булса да, әлеге бүләкне алган булыр иде әле. Шунысы да кызык, әлеге орден XIII гасырда Мәскәүне монгол татар басып алучыларыннан саклаганда батырлыклар күрсәтеп дан казанган кнәз Даниил истәлегенә булдырылган. Инде орден иясе Минтимер әфәнде үз чиратында Мәскәүнең күңелен «яулап» Татарстанга ирек алырга китмәде микән? Русия башкаласының 850 еллык юбилеена багышланган очрашуларда ул төбәкләргә күбрәк мөстәкыйльлек бирергә кирәк дип сөйләгән.

**(«Татарстан яшьләре» газетасыннан).**

### Милләтсез паспортлар булачак

Русия эчке эшләр министрлыгының паспорт - виза идарәсе җитәкчесе генерал - майор Владимир Колесников ил гражданнары 1 октябрьдән яңа паспортлар ала башлаячаклар дип белдерде. Иң беренче номерлы паспортларга Мәскәү кешеләре хуҗа булачак. Тагын шунысы да бар: 14 яше тулган һәркем үзен граждан дип саный ала. Яңа паспортта СССР дигән сүз, урак - чүкеч рәseме һәм «милләт» дигән графа юк. Русиядә яшәүчеләр иске паспортларын яңаларына 2005 елның 31 декабренә кадәр алыштырып бетерергә тиешләр. Паспорт реформасы дәүләт казнасына «нибары» 2,5 триллион сумга төшкән.

**(«Татарстан яшьләре» газетасыннан).**

## Бәйрәмгә тагын бер бүләк

Норлат халкының еллар буе су, су диеп типкән йөрәкләре, шөкер, быел канәгатьләндерелде дияргә мөмкин. Яңа су килгән Кормыш поселогы халкы моңа кадәр нефть - бораулаучыларның артезиан скважиналарына ныклы сукмак салганнар иде: бирегә су тәмле дә, чишмәсе беркайчан өзелми дә. Бүген дә халык бирегә эзен югалтмады, шуңа да быел предприятие саф, чиста суын Норлат халкы белән ачыктан - ачык бүлешергә булды. Совет урамын үтеп йөрүчеләр игътибар иткәндер: иске профилакторий янында ял эскәмияләре, дугасыман күперчеге белән куаклар ышыгында зәвык белән эшләнгән урын барлыкка килде. Шул матур күренеш уртасында салкын суы ургылып ага торган колонка шәһәрдә яшәүчеләрне дә, үтеп йөрүчеләрне дә куандырачак. Бу изге һәм файдалы эш вышка монтажлау цехы тырышлыгы һәм, әлбәттә, предприятие җитәкчелегенең халык ихтыяҗларына игътибарлы карашы аркасында барлыкка килде.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**



Әхтәм абыйсы Рамилнең этисе яшендәге кеше. Шуңа да ул аны өлкән яшьтәге кеше буларак бер хөрмәт итсә, хезмәттәшенең тормыш, хезмәт тәҗрибәсен күреп, аңа булган ихтирамы тагын да арта. Тырыш, үз эше өчен җаваплы булмаса, шулай чирек дистә ел дәвамында берәзлексез шофер булып эшли дә алмаган булыр иде, мөгаен. Әле ничек эшли диген! «КамАЗ» автомашинасына утыруына да 15 еллап бит инде. Ә бу төр автотранспорт өчен авылда эшнең һичкайчан бетеп торганы юк. Әхтәм исә җил урынына ерак шәһәрләргә дә барып кайта, хуҗалык эчендәге эшләргә дә өлгерә. Өендә дә тәртип. Мөстәкыймовлар гаиләсе авылдагы үрнәк гаиләләрнең берсе. Кызларының берсе югары белем алып, Чулпан мәктәбендә укыта. Икенчесе дә озакламый һөнәрле булачак.

Шуңа да Рамил гел Әхтәм абыйсы янында булырга, аннан үрнәк алырга тырыша. Ә аның кебек тормышны әле яңа башлаган кеше өчен бу бик мөһим. Дөрес, Рамилнең дә аз булса да тәҗрибәсе бар. Тракторда да эшләгәне бар, комбайнда да. Инде менә «КамАЗ» автомашинасын йөртә.

**Рәсемдә: «40 лет Победы» КФХАсы шоферлары Ә.Мөстәкыймов, Р.Вәлиәхмәтов.**
**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## Синең кешеләрең, Норлат

# ТУГЪРЫЛЫК



Әгәр ул шул вакытта өйләнмичә, вакытны сузыбрак торса, мөгаен, туган авылы Киекледә үк калган да булыр иде.

Читтән килеп җирле мәктәптә укытучы булып эшләүче, үзешчән сәнгать түгәрәгендә бергә биеп йөрүче Алсу Хәбибулловнага Алабуга пединститутына кышкы сессиягә китәсе көннәрдә генә тотты да кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Алсуы да ризалашты да куйды.

Шулай итеп, кичәге сержант, хәзерге колхоз бригадиры ярдәмчесе белән укытучы кыз туй ясадылар.

Менә шунда гаиләне ничек тәэмин итәргә дигән сорау туа. Һәммәсе дә яхшы булсын өчен, ныклы терәк булу шарт. Бу терәк исә - эш. Димәк, чын һөнәр, даими торак табарга кирәк.

6 балалы - 6 уллы эшчән гаиләдә үскән Рафик бер хезмәттән дә курыкмый иде.

Чын һөнәр сайлаганчы 2 еллап вакыт узды. Алар гаиләләре белән Лениногорскига, нефтьче булып эшләүче Вазыйх агалары янына киттеләр. Рафик Вәлиәхмәтович хәзергә кадәр Лениногорск нефть чыгаручыларын җылы итеп искә ала: алар эшкә урнашу кыен булган 1976 елда аны үз эшче гаиләләренә кабул иттәләр, һөнәргә өйрәтәләр һәм Рафик 20 елдан артык шул һөнәргә тугърылык саклап яши.

Шул елларда аның хезмәт кенәгәсендә беренче язу пәйда булды да: скважиналарны җир асты ремонты буенча оператор итеп кабул ителде. Шуннан бирле бу кенәгәдә бары тик аның квалификацион разрядын күтәрү турында гына билгеләр. Тагы 1979 елда шул ук һөнәрдә аны туган ягы Норлатта яңа ачылган нефть - газ чыгару идарәсенә күчерү турында язу бар.

- Беренче адымнарыбызны ясаганда, төрле кыенлыклар да булды, аларны бик авыр кичерә идем,- дип искә ала Р.Хәмәтвәлиев. - Аның каравы, беренче кыр сезонында ук күп нәрсәгә өйрәндем, махсус әдәбият укыдым, иптәшләрем тәҗрибәсенә колаксалдым. Осталык шулай акрынлап килде. Ә минем һәрчак үз эшемнең остасы буласым килә иде...

Рафикны Хезмәт Даны Ордены белән бүләкләүгә әзерләгән вакытта миңа (ул чакта мин НГДУның кадрлар бүлеге начальнигы идем) аның белән якыннан танышырга туры килде. Бар яктан да килгән иде ул: әйбәт костюм, ап - ак күлмәк, чиста итеп кырынган, пөхтә мыеклы, килешле чәчле, сабыр холыклы - һәммәсе ныклы, тәртипле, ышанычлы.

Эш урынында да шундый ул: тыныч, сабыр, пөхтә.

- 15 елдан артык Рафик Вәлиәхмәтович иң югары 6 нчы разряд буенча эшли,- дип сөйли, скважиналарга җир асты ремонты бригадасы мастеры Рафик Сингатуллин. - Әгәр сменада аның вахтасы икән, мин тулысынча ышанам: һәммә эш тиешенчә башкарылачак, һәр хезмәтне җиренә җиткереп үтәячәк. Бер сүз белән әйткәндә, ышанычлы кеше ул, чын белгеч тә. Ярдәмче оператор Халит Шәкүров һәм күтәрткеч машинисты Насыйх Гайсин да вахта буенча өлкән иптәшләре турында шундый фикердә.

Бу еллар эчендә аңарда ярдәмче (димәк, өйрәнчек!) булып күпләр эшләде. Хәзер алар үзләре вахта белән җитәкчелек итәләр, кайсылары мастер сыйфатында бригадалар белән җитәкчелек итәләр.

Рафик Хәмәтвәлиевнең үзенә скважиналарны ремонтлау буенча мастер урыны тәкъдим иттеләр һәм итәләр дә. Әмма ул гел бер җавапны бирә: мин үз урынымда. Кеше урынын аласым килми.

Аның куллары белән йөзләгән скважина төзекләндерелде. Ә бу - тонналаган нефть дигән сүз. Нәкъ шундый әзерлекле белгечләр, чын хезмәткәрләр тырышлыгы нәтиҗәсендә «Норлатнефть» НГДУсы елдан - ел нефть чыгаруны арттыра бара.

Рафикның гаиләсендә дә дәрәҗәсе зур.

- Бик ышанычлы кеше инде,- ди Алсу Хәбибулловна ире турында. - 20 елдан артык бергә яшәү чорында төрле шартларда да мин гел шуңа инана килдем. Ул гына түгел, ага - энеләре дә шундыйлар. Алар һәммәсе эш өчен яралганнар. Чын хезмәт кешеләре.

Шунысын әсти алабыз: бертуган Хәмәтвәлиевларның икесе - нефтьчеләр, калганнары һәркайсы үз һөнәре буенча авыл хуҗалыгында эшлиләр. Ә язмабыз башында телгә алынган Вазыйх Мәскәү нефть һәм газ институтын тәмамлап, «Лениногорскнефть»тә әйдәп баручы инженер - ЦПКРС начальнигы урынбасары булып эшли. Дөрес, аның фамилиясе бераз бүтәнчәрәк языла - Мөхәммәтвәлиев. Алсу Хәбибулловна да кайчандыр үзе сайлаган һөнәргә тугъры калды. Хәзер ул Норлатта балалар бакчасы мөдире. Ә менә уллары Радик әтисе эзеннән китте - Казан дәүләт педагогия университетының III курсында укый, тарихчы булырга ниятли.

Ә нәрсә, безгә үз куллары белән тарихны тудыручылар кебек үк тарихчылар да кирәк.

**В.БУРАЙКИН.**

**Норлат шәһәре.**

**«Норлатнефть» НГДУсының скважиналарга җир асты ремонты операторы, III дәрәҗә хезмәт даны ордены кавалеры, нефть промышленносте отличнигы Рафик Хәмәтвәлиев.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**



Александр Ильмухин - «Агрохимсервис» АҖ ярдәмче хуҗалыгының иң алдынгы механизаторларының берсе. Иртә яздан алып кара көзгә кадәр басуда була ул. Җир сөрә, чәчә, аннан үсемлекләр карый. Тырышып эшли Александр.

Бүгенге көндә механизатор Ильмухин басуларны туңга сөрү белән мәшгуль.

**Рәсемдә: А.Ильмухин.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ИҢ БЕРЕНЧЕ КЕШЕ...

М.Шәймиев урыс православие чиркәве орденын алган бердәнбер мөселман димәкче булабыз. Русия тарихында мондый хәлнең булганы юк икән. Алексий II - нең М.Шәймиевкә әлеге орденны тапшыруын телевизордан карап утырганда, их, патриарх башына да татар түбәтәе кидертергә иде дип уйлап куйдым. Алексий II дә әдәп саклап булса да, әлеге бүләкне алган булыр иде әле. Шунысы да кызык, әлеге орден XIII гасырда Мәскәүне монгол татар басып алучыларыннан саклаганда батырлыклар күрсәтеп дан казанган кнәз Даниил истәлегенә булдырылган. Инде орден иясе Минтимер әфәнде үз чиратында Мәскәүнең күңелен «яулап» Татарстанга ирек алырга китмәде микән? Русия башкаласының 850 еллык юбилеена багышланган очрашуларда ул төбәкләргә күбрәк мөстәкыйльлек бирергә кирәк дип сөйләгән.

**(«Татарстан яшьләре» газетасыннан).**

### Милләтсез паспортлар булачак

Русия эчке эшләр министрлыгының паспорт - виза идарәсе җитәкчесе генерал - майор Владимир Колесников ил гражданнары 1 октябрьдән яңа паспортлар ала башлаячаклар дип белдерде. Иң беренче номерлы паспортларга Мәскәү кешеләре хуҗа булачак. Тагын шунысы да бар: 14 яше тулган һәркем үзен гражданин дип саный ала. Яңа паспортта СССР дигән сүз, урак - чүкеч рәсеме һәм «милләт» дигән графа юк. Русиядә яшәүчеләр иске паспортларын яңаларына 2005 елның 31 декабренә кадәр алыштырып бетерергә тиешләр. Паспорт реформасы дәүләт казнасына «нибары» 2,5 триллион сумга төшкән.

**(«Татарстан яшьләре» газетасыннан).**

## Бәйрәмгә тагын бер бүләк

Норлат халкының еллар буе су, су диеп типкән йөрәкләре, шөкер, быел канәгатьләндерелде дияргә мөмкин. Яңа су килгән Кормыш поселогы халкы моңа кадәр нефть - бораулаучыларның артезиан скважиналарына ныклы сукмак салганнар иде: биредә су тәмле дә, чишмәсе беркайчан өзелми дә. Бүген дә халык бирегә эзен югалтмады, шуңа да быел предприятие саф, чиста суын Норлат халкы белән ачыктан - ачык бүлешергә булды. Совет урамын үтеп йөрүчеләр игътибар иткәндер: иске профилакторий янында ял эскәмияләре, дугасыман күперчеге белән куаклар ышыгында зәвык белән эшләнгән урын барлыкка килде. Шул матур күренеш уртасында салкын суы ургылып ага торган колонка шәһәрдә яшәүчеләрне дә, үтеп йөрүчеләрне дә куандырачак. Бу изге һәм файдалы эш вышка монтажлау цехы тырышлыгы һәм, әлбәттә, предприятие җитәкчелегенең халык ихтыяҗларына игътибарлы карашы аркасында барлыкка килде.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**




Әхтәм абыйсы Рамилнең әтисе яшендәге кеше. Шуңа да ул аны өлкән яшьтәге кеше буларак бер хөрмәт итсә, хезмәттәшенең тормыш, хезмәт тәҗрибәсен күреп, аңа булган ихтирамы тагын да арта. Тырыш, үз эше өчен җаваплы булмаса, шулай чирек дистә ел дәвамында берәзлексез шофер булып эшли дә алмаган булыр иде, мөгаен. Әле ничек эшли диген! «КамАЗ» автомашинасына утыруына да 15 еллап бит инде. Ә бу төр автотранспорт өчен авылда эшнең һичкайчан бетеп торганы юк. Әхтәм исә җил урынына ерак шәһәрләргә дә барып кайта, хуҗалык эчендәге эшләргә дә өлгерә. Өендә дә тәртип. Мөстәкыймовлар гаиләсе авылдагы үрнәк гаиләләрнең берсе. Кызларының берсе югары белем алып, Чулпан мәктәбендә укыта. Икенчесе дә озакламый һөнәрле булачак.

Шуңа да Рамил гел Әхтәм абыйсы янында булырга, аннан үрнәк алырга тырыша. Ә аның кебек тормышны әле яңа башлаган кеше өчен бу бик мөһим. Дөрес, Рамилнең дә аз булса да тәҗрибәсе бар. Тракторда да эшләгәне бар, комбайнда да. Инде менә «КамАЗ» автомашинасын йөртә.

**Рәсемдә: «40 лет Победы» КФХАсы шоферлары Ә.Мөстәкыймов, Р.Вәлиәхмәтов.**
**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# Милләтнең олы шагыйре



II Бөтендөнья татар конгрессы программасына аның мөһим эшләреннән берсе итеп урта гасырлар шигъриятебезнең иң якты йолдызларыннан булган Мөхәммәдъярның 500 еллыгын тантаналы төстә билгеләп үтү кертелде.

Татарстан хөкүмәте карары белән 1997 ел безнең республикабызда Мөхәммәдъяр елы дип игълан ителде. Мондый карар өчен ныклы тарихи нигез һәм кайбер үрнәкләр дә бар.

Халкыбызның легендар чичәне һәм фикер иясе Мәхмүд Хаҗи углы Мөхәммәдъярның биш гасырлык юбилее дәүләт дәрәҗәсендә билгеләнеп үтелә. Әйтергә кирәк, тарихның кырыс сынауларын үтеп, үлемсезлеккә юл алган иҗаты белән Мөхәммәдъяр мондый ихтирамга күптән лаек.

Милли җанлы шагыйрь туган халкы язмышының гаять киеренке, хәтта драматик төс алган чорында яши һәм иҗат итә.

Үткәннән килә торган бай мәдәнияттан рух һәм тәм алып, шул ук вакытта туган иленең язмышы кыл өстендә торган шартларда иҗат итү ватанпәрвәр Мөхәммәдъяр шигъриятенә тирән эз сала, аның максатын һәм аһәңен билгели.

Мөхәммәдъяр әсәрләреннән парчалар

## Күк сандугачы
## («Төхфәи мәрдан»)

Мөхәммәдъяр, сиңа биргән Хакъ телне,-
Күк бакчасында бу сайрар былбылны.

Читен, хәтта аз шигырь да сөйләсәң,
Ирме соң син үз хәлеңне димәсәң!

Күпләр сөйләп бу дөньядан кичтеләр,
Сөйләү белән энҗе - дөрләр чәчтеләр.

Күпләр сөйли алмый,- сүзен кистеләр,
Күрә алмыйча, тән тишеп, кан эчтеләр.

Гакълың булса, җирдә калдыр сүзеңне,
Укыганнар ахыр данлар үзеңне...

Сөйлә татлы шигырьләрең мул сачеп,
Бу - табигать биргән сазга юл ачып.

Йөрәгеңне утта яндыр бу эштә,
Егетләрчә билең бәйлә һәр төштә.

И Илаһым, сиңа мәгълүмдер бу эш,
Тик бир миңа ялкынлы дәрт, хуш йөреш.

Сөйләгәндә йөзем һәрчак ак булсын,
Сүзләрем халыкка йомшак - пакъ булсын...

Минем эшем Илаһ биргән көчтәдер,
Бар сулышым халык өчен эштәдер.



## Мөхәммәдъяр кайтты

Узган ел артист Айдар Хафизов Бакуга Фөзүлинең 500 еллык тантанасына барып, әзәриләрнең үз шагыйрьләрен ничек зурлауларын күреп, исе китеп кайтты. Моңа кадәр ул, әлбәттә, Фөзүлине дә, Мөхәммәдъярны да яхшы белә иде. Шигырьләрен яттан сөйли иде. Ләкин бер чорда яшәп, бер - берсен белешеп иҗат иткән бу шагыйрьләр бөек философлар, акыл ияләре дә икән. Татар үзенең Мөхәммәдъярын беләме соң? Белә, әмма, Инша Аллаһы, моннан соң аны тагын бик күпләр яңа яктан ачачаклар. Г.Камал театры артистлары, галимнәр, тарихчылар, фольклорчылар, шагыйрьләр Мөхәммәдъярга багышлап, матур тамаша - спектакль иҗат иткәннәр. Аны куючы да, төп рольне уйнаучы да Айдар Хафизов.

**Рәсемдә: Мөхәммәдъяр - Айдар Хафизов, хан - Ринат Таҗетдин.**

**Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотосы.**

# Тәмле тамак кухнясы



## Фаршлаган помидор

Яхшылап юылган помидорның төбен үткен пычак белән тигез итеп кисеп алалар, кашык белән эчен чистарталар, эченә тоз сибеп, суы саркысын өчен киселгән ягы белән тезеп куялар. Бераздан помидорлар эченә әзер фаршны тутыралар да, петрушка сабагы кадап, нәзек кенә буйга киселгән кыяр телемнәре белән бизәп, киселгән помидор «түбәтәйләре» белән кыеклап ябып куялар. Тиз әзерләнә торган менә дигән тәмле ризык!

Моның өчен уртача зурлыктагы 8 помидор, тоз, петрушка ботаклары, 2 - 3 кыяр кирәк.

Фарш болай ясала: 50 грамм атланмай кушып, 2 пешкән йомырканы вак итеп турап болгаталар, лимон согы (1 - 2 тамчы), тоз һәм төелгән кара борыч кушалар.

## Алма бөккәне

Йомыркага шикәр кушып болгатып күпертәләр, ярты стакан үсемлек мае, бер чеметем сода, корица һәм кыргычта уылган алманы он кушып яхшылап болгаталар. Майланган һәм бераз он сибелгән духовка калаена камыр җәеп, әзер эчлекне салып, өстен юкарак җәймә камыр белән ябалар да, кырларын матурлап бөгеп, духовка миченә куялар.

Алма бөккәне өчен 2 стакан он, 3 йомырка, 8 чәй кашыгы май, 1 чәй кашыгы сода, 1 чәй кашыгы корица, 20 грамм атланмай һәм 600 грамм алма кирәк.

***Ашыгыз тәмле булсын!***

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерлебез ***Надыйр Нәгыйм улы Вәлиевка*** бу көннәрдә 55 яшь тула. Аны чын күңелебездән юбилее белән котлап, нык сәламәтлек, бәхетле көннәр, эшендә уңышлар телибез. Киләчәктә дә һәммәбезгә олы киңәшче, ныклы терәк булып, без балаларының кадер - хөрмәтен күреп аңа озак еллар яшәргә насыйп булсын иде.

***Тормыш иптәше, улы, кызы, кияве, оныгы.***

*Кадерле әтиебез, тормыш иптәшем **Мингазыйм Рәхимҗан улы Идиятуллинга** 14 сентябрьдә 55 яшь тула.*

*Әти! Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз, сәламәтлек, бәхет һәм әни белән тигез гомер кичерүегезне телибез.*



*Бүген менә 55ең тула,*
*Шатлыгы да күптер, моңы да*
*Гел куанып кына җир йөзендә*
*55 ел яшә тагын да.*

***Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, кияүләрең, оныкларың.***

# Белдерүләр

## САТАБЫЗ

**1996 елгы гранат төсендәге ВАЗ - 21093.** Тел.: 5 - 21 - 84.

***

**«Урал» мотоциклы, кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 18 - 24.

***

**Йорт (гаражы, мунчасы, коесы, базы, 11,5 сутый җир участогы бар).** Адрес: Киров ур., 36.

***

**Ашыгыч төстә бер бүлмәле фатир.** Адрес: Дружба ур., 75 - 68, тел.: 65 - 5 - 11 (17 сәг.тән соң).

***

**Ашыгыч рәвештә 2 бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 16 - 28.

***

**Матур туй күлмәге, тотылган балалар җиһазы, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 18 - 84.

***

**Тоннасы 8 млн.нан аккумулятор кислотасы, бартер мөмкин.** Адрес: Яр Чаллы шәһәре (88552) 46 - 87 - 20. Лицензия сериясе Б - 97, № 081304.

***

**1994 елгы «Нива» ВАЗ - 21213, 40000 км. юл үткән.** К.Маркс урамындагы «Автозапчасти» кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**ВАЗ - 21099.** Адрес: Гагарин ур., 14 - 5.

***

**Первомайская урамында 13 нче йорт сатыла.** Тел.: 65 - 5 - 40, 18 сәг.тән соң.

***

**Әфган поселогында 10 сутый җире белән төзелеп бетмәгән кирпеч йорт, бәясе - чыдарлык.** Тел.: 2 - 22 - 50.

***

**ВАЗ - 21013 «Жигули» автомашинасы, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 20 - 63 (17 сәг.тән соң).

***

**Кече Камышлы авылында йорт.** Урта Камышлы авылында Муляков Николайга мөрәҗәгать итәргә.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Үз материалыгыздан йорт, гаражлар (арзан һәм сыйфатлы) төзибез. Төзелеш материаллары (такта) белән исәпләшергә мөмкин.** Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗипне сорарга.

***

**Яшь гаиләгә 1 бүлмәле, уңайлыклы фатир кирәк.** Тел.: 5 - 17 - 99.

***

**СО2гә дәүләт һәм шәхси машиналарны тикшерү.** Авторота бинасында (АТП).

***

**2 нче каттагы 3 бүлмәле фатир 2 берәр бүлмәлегә алыштырыла.** Адрес: Завод тыкрыгы, 7 - 5, (17.00сәг.тән 21.00гә кадәр).

***

**Өч кешелек гаиләгә яшәп торырга фатир кирәк.** Тел.: 2 - 15 - 68 (18 сәг.кә кадәр).

***

**Яшәп тору өчен бер бүлмәле фатир бирәм.** Адрес: Циолковский ур., 11 - 17 (10нан 17 сәг.кә кадәр мөрәҗәгать итәргә).

**Тимер юл эшчеләрне тәэмин итү бүлегенә йөкчеләр, электрик, шоферлар кирәк.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә.